| ГЛАВА<br>Кучуковского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Көчек авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2019 Түбән Көчек авылы № 5

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Көчек авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге башлыгы карар бирде:

1.2019 елның 28 ноябрендә Көчек авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 14 сәгатькә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: «I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан тыш, Көчек авыл җирлегендә теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Түбән Көчек авылында Калинин һәм Казан урамнарына вак таш түшәү.
2. Түбән Көчек авылының Яңа урамында су челтәрен алыштыру.
3. Түбән Көчек авылы суэтем башнясына тирәнгә насос сатып алу.
4. Түбән Көчек авылы суэтем башнясын санитар саклау йөзеннән койма белән әйләндереп алу.
5. Түбән Көчек авылы зират коймасын тоту.
6. Түбән Көчек авылы янгын сүндерү машинасының штаттан тыш хезмәткәренә хезмәт хакы түләү.
7. Түбән Көчек авылында Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү.

8. Кеше тормышына һәм сәламәтлегенә яный торган корыган агачларны кисү.

9. Түбән Көчек авылы юлларын кыш көне кардан чистарту.

«ӘЙЕ»      «ЮК»

3.Көчек авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Кучуковского сельского поселения
Көчек авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002526

Р.Ә.НУРМӨХӘМӘТОВ